***Кузьмина Халиса Хатиповна***
Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ АТКАЗАНГАН ПРОФЕССОРЫ ВАХИТ ХӨҖҖӘТ УЛЫ ХАКОВ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*В статье описываются основные этапы жизни и деятельности основателя научного направления по истории татарского литературного языка профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова.*

**Ключевые слова**: *Хаков, история языка, лингвистика, периодизация, персоналия.*

*The article describes the main stages of life and activities of the founder of Tatar literary language history school, Kazan University professor Vahit Khozyatovich Khakov.*

**Key words:** *Khakov, language history, linguistics, periodization, personalia.*

Фән тарихында тормыш авырлыкларына карамый, үз юлыннан читкә тайпылмый, хакыйкый белемгә йөз тоткан һәм үз артыннан яшь буынны алып барырлык сәләткә ия булган шәхесләр бар. Шундыйларның берсе − Казан дәүләт университетының атказанган профессоры, Россия Гуманитар фәннәр Академиясе академигы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты, Бөек Ватан сугышы ветераны, филология фәннәре докторы Вахит Хөҗҗәт улы Хаков. Төрле тарихи чорларда, җәмгыять үсешенең төрле тайпылышларында һәм борылыш чорларында яшәргә туры килсә дә, Вахит Хөҗҗәт улы һәрвакыт рухи чыдамлык, максатчанлык, тәрбиялелек һәм зыялылык үрнәге булып торды.

«Фән тарихы ике тарихка бүленә: аның берсе − объективлаштырылган, ягъни субъектларга бәйле булмаган идеяләр тарихы, икенчесе − шәхес (персоналий) тарихы, ягъни иҗтимагый, сәяси, дини һ.б. контектска утыртылган галимнең белем барлыкка китерү өлкәсендәге эшчәнлеге» [Купцов, 1996: 362] Мәкаләдә икенче тарих − шәхеснең галим буларак җитлегү тарихы турында сүз барачак. Әлеге хезмәтнең актуальлеге төрки тел белемендә соңгы елларда фәнгә сизелерлек өлеш керткән галим-шәхесләр тарихына (персоналийларга) кызыксыну артуы белән дә аңлатыла. Шул ук вакытта энциклопедик хезмәтләр һәм төрки лингвистик фикер үсеше тарихын язу өчен дә әлеге мәкалә актуаль булыр дип уйлыйбыз.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның тормыш юлы, ул елларда яшәгән йөзләрчә галимнеке кебек үк, гади һәм гадәти. Әмма бу − беренче карашка гына. Егерменче гасырның шаукымлы елларын кичергән кеше буларак, ул бәхетле язмышка ия. 1926 нчы елның 16 августында Буа районы Күзби авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Шәҗәрәсендә – укымышлылар гына. Бабасы

– Күзби авылы мулласы Габделхак хәзрәт. Әтисе – Хөҗҗәт Хаков – кызылармеец, Перекопны Врангель гаскәрләреннән азат итү сугышларында катнашкан, яралангач, туган авылы Күзби авылына кайтып, беренче совет мәктәбе ачкан, озак еллар шунда мөгаллимлек иткән. Әни назын күрә алмый үскәнгә (әнисе − Буа районы Чәчкаб авылы Мортаза ишан кызы Бибигайшәне авыр елларда туганнары Үзбәкстанга алып китәләр), әтисенең әнисе Галия әби нәни Вахит өчен гаилә җылысын бирергә бар көчен куя. Әтисенең сеңелләре Гыйзелнәвал һәм Рабига мәктәпкә укырга кергәнче үк Вахитка гарәп язуын өйрәтәләр. Белемгә омтылучан, тырыш, хезмәтчән булып үсә Вахит. Ундүрт яшендә ул − район газетасының актив хәбәрчесе, Абдулла Алиш белән хат алыша, әтисе китапханәсендәге борынгы китапларны укый, язу серләрен өйрәнә. Әмма коточкыч афәт − сугыш башлана, ирләр фронтка киткәннән соң, бөтен авырлык, колхоз эшләре хатын-кызлар һәм яшүсмер балалар җилкәсенә төшә. Бу вакытта аңа нибары 14 яшь кенә була әле. Вахит та өч елга якын шушы тормыш белән яши. 1943 елның ноябрендә исә 17 яшендә ул да фронтка алына. Монголия, Кытай чигендә япон самурайларының Квантун армиясенә каршы көрәшләрдә катнаша, разведчик була. Сугыш кайтавазын Вахит ага беркайчан да онытмый, сиксән яшьлек юбилее уңаеннан чыгарылган китапта сугышта булган һәр вакыйганы махсус бүлекчәгә урнаштыра һәм шәкертләрен дә «Сугыш еллары минем киләчәк тормышымның юнәлешен хәл итүдә бик зур роль уйнады», − дип искәртә. [Туган як..., 2007: 7] Монголия далаларында ул беренче тапкыр төрки рун хәрефләре язылган ташларга юлыга, аларның тарихы белән таныша.

1949 нчы елның гыйнварында демобилизацияләнгәннән соң, Вахит туган авылына кайта һәм авыл советы сәркатибе, соңрак Буа районы Казма һәм Бик-Үти авылларында укытучы булып эшли. Әтисенә дә ике тапкыр сугышка китеп, яраланып булса да, исән-сау кайтырга насыйп булган. Вахит 1951-1957 елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында читтән торып укый, аны кызыл дипломга тәмамлый. Сәләтле егетне аспирантурага чакыралар, ул 1960 елга кадәр аспирантурада белем ала һәм мең биткә якын диссертациясен уңышлы яклый. Галимнең фәнни эшчәнлек юлы шушы еллардан башлана. Башта СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының кече фәнни хезмәткәре, аннан соң Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасы ассистенты итеп эшкә алына. Өч елдан Вахит Хөҗҗәт улы доцент дәрәҗәсенә күтәрелә, тугыз елдан «Татар әдәби теле һәм аның стильләренең барлыкка килүе һәм үсеше» дигән темага докторлык диссертациясен яклый һәм профессор дәрәҗәсенә ирешә [Туган як..., 2007: 8]. Әлбәттә, мондый баш әйләндергеч тизлектә хезмәт карьерасы буйлап күтәрелү җиңел генә бирелми. Вахит Хаковның бер-бер артлы тел тарихына багышланган китаплары дөнья күрә, мәкаләләре басыла, галим архивлардан яңа чыганаклар эзләп таба һәм аларны кулланышка кертеп җибәрә [Туган як..., 2007: 163-201]. Алай гына да түгел, татар тел гыйлемен халык арасында

популярлаштыру максатында радио һәм телевидениедә тел тарихы буенча тапшырулар эшли, газета-журналларда сүзләр тарихы, борынгы әдәби әсәрләр һәм аларның теле турында язмалар урнаштыра. 1975 нче елдан алып, хәзерге көнгә кадәр Татарстан радиосында Вахит ага оештырган «Тел күрке − сүз» тапшыруы бара. Аның халык арасындагы популярлыгы совет елларында искиткеч зур була, хәзерге вакытта да халык әлеге тапшыруны яратып тыңлый.
Шул рәвешле, илле елга якын гомерен Вахит Хөҗҗәт улы Хаков югары уку йортында фәнни һәм педагогик белем бирүгә багышлаган. Тюрколог галим буларак, Вахит Хаков татар теле белемендә «Төрки әдәби телләр үсеше» юнәлешен башлап җибәрүчеләрнең берсе була һәм татар әдәби теленең хосусан кызыклы үз үсеш юлы барлыгын дәлилли. Университетта эшләү дәверендә ул «Борынгы төрки һәм төрки-татар язма чыганакларның телен диахроник һәм синхроник аспектта өйрәнү, хәзерге татар әдәби телен формалаштыруда аларның роле» дигән фәнни теманың җитәкчесе булып тора. Галимнең фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе булып, 27 китап, дәреслек һәм уку-укыту әсбабы (шуларның унысы − монография), 500дән артык мәкалә дөнья күргән, аның җитәкчелегендә егерме кандидатлык диссертациясе якланган һәм ул өч докторлык диссертациясенең фәнни консультанты булып торган. «Тел һәм стиль мәсьәләләре» (1961), «Татар теле стилистикасына кереш» (1963), «Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше» (1972), «Татар әдәби теле тарихы (Татар теленең борынгы заманнан хәзерге чорга кадәр үсеше турында)», Татар әдәби теле. Стилистика» (1999), «Тел − тарих көзгесе» (2003) һ.б. китапларында төрле жанрга караган бик күп чыганакларның теле яктыртыла, аларга җентекле анализ бирелә һәм фәнни дөньяга тәкъдим ителә.

Галимнең хезмәтләре арасында аның «Тел − тарих көзгесе» дип аталган хезмәте аеруча лаеклы урын тота [Хаков, 2003]. Соңгы монографиясе буларак, биредә галимнең тел тарихына караган төп фикерләре, эзләнүләре, табышлары җыеп бирелгән. Хезмәттә билгеле бер системага салынып, борынгы чордан хәзерге көнгә кадәр татар әдәби теле нормалары һәм стильләренең үсеше күзаллана, күп гасырларга сузылган татар язма традицияләренең башка төрки язма телләр арасындагы урыны билгеләнә, татар әдәби теленең милләткәчә һәм милләт барлыкка килгәннән соңгы чордагы үсеш үзенчәлекләренә басым ясала. «Тел − тарих көзгесе» хезмәтендә түбәндәге мәсьәләләр куела һәм аларның чишелеше тәкъдим ителә:

1) Татар әдәби теле үсеше тарихының теоретик нигезләре (чыганаклар, традицияләр, сөйләмә һәм язма формалар арасындагы уртаклык һәм аермалар, татар әдәби телләрнең үсешен чорларга бүлү һ.б.) [Хаков, 2003: 36];

2) Татар әдәби теленең милләткәчә булган чоры: а) Идел буе төркисенең нормалары һәм стиль төрләре формалашу һәм үсеше (болгар чоры); Алтын Урда чоры әдәби теле; в) Казан ханлыгы чоры әдәби теле [Хаков, 2003: 71];

3) Татар әдәби теленең милләт барлыкка килгәннән соңгы чоры: а) XVII-XVIII гасырларда фонетик, грамматик һәм лексик нормаларның ныгуы; б) XIX гасыр татар әдәби теле; в) татар милли әдәби теленең барлыкка килү һәм үсү чоры; г) XX гасыр татар әдәби теле; в) аерым язучылар теле [Хаков, 2003: 81-241].

Шул рәвешле, әлеге хезмәт − озак елларга сузылган дәвамлы эшчәнлек нәтиҗәсе һәм татар тел гыйлеме фәненең зур казанышы. «Тел − тарих көзгесе» хезмәтендә тел гыйлемендә беренче тапкыр татар әдәби теленең үсеше чорларга бүленеп карала, һәр чорның үзенчәлекләре билгеләнә, үсеш траекториясе күзаллана. Хезмәт дөньякүләм стандартларга җавап бирерлек дәрәҗәдә югары кимлдә башкарылган.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков фәнни эшчәнлеген иҗтимагый эшчәнлек белән бәйләп алып барды. Ул озак еллар дәвамында университетның профсоюз һәм партия оешмаларында эшләп, халыкка хезмәт күрсәтте. «Татарстан Республикасы телләре турындагы Закон»ны гамәл кую юнәлешендә дә галимнең өлеше зур: латин язуын кулланышка кертү өчен берничә уку-укыту әсбаплары төзеде, халык арасында агарту-мәгърифәт эшчәнлеге алып барды.

Вахит ага кеше буларак та олы хөрмәткә ия, аның әхлакый яктан камил, тәрбияле, зыялы булуы күпләрне сокландыра иде. Хатыны Хөррия ханым белән ике бала тәрбияләп үстерүләре, Вахит аганың хаҗга сәяхәт кылуы мәгълүм. 1994 нче елда ул Австралиядәге «Җир шарында Гуманизм һәм Гаделлек өчен» дип аталган Халыкара Рыцарьлар Конфедерациясенә әгъза буларак кабул ителә, бу оешманың ордены белән бүләкләнә. Бүләкләре һәм мактаулы исемнәре бик күп Вахит аганың. Унсигез орден һәм медальләрдән тыш, аның санап бетергесез Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары бар... [Туган як..., 2007: 11]. Биредә аның 2006 нчы елда фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт Премиясе лауреаты булуын искә алу да җитә. Дәүләтебез галимнең фидакарь эшчәнлеген күргән һәм гадел бәяләгән.

2008 нче елның 20 июнь көнне 81 яшендә татар теле фәненең классик галиме Вахит Хөҗҗәт улы Хаков вафат булды. Тюркология үзенең олы галимен югалтты, һәм бу югалту ачысы бүгенге көндә дә үзен сиздерә. Мөхтәрәм галимебез, остазыбызның якты хатирәсе безнең күңелләрдә мәңге сакланыр.

**Әдәбият**

Купцов, В.И. Философия и методология науки / В.И. Купцов. – Москва: Аспект-Пресс, 1996. – 552 с.

Туган як һәм туган тел хисе (сост. Х.Х. Кузьмина). – Казан, КДУ нәшрияты, 2007. – 220 б.

Хаков, В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан) / В.Х. Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.